ЯКШӘМБЕ
14
МАРТ
1943 ел.
№ 59 (6781)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

КОМСОМОЛ ЭШЕН ХӘЗЕРГЕ БУРЫЧЛАР ЮГАРЫЛЫГЫНА!

Илебез кичерә торган хәзерге момент комсомол оешмаларыннан һәм һәрбер комсомолецтан фронтка ярдәмне тагын да арттыруны таләп итә. Хәзер, бөек ватан сугышы чорында, комсомол оешмаларының роле аеруча зур. Алар, фронт өчен эшләүче безнең тылыбызда киң массаны чын-чыннан оештыручы, хезмәт иясе яшьләрне яңа уңышларга рухландыручы булырга тиешләр. Алар совет яшьләрен политик яктан һәм югары патриотизм рухында тәрбияләү эшенең башында торырга, предприятиеләрдә безнең производство тормышы белән тирәнтен кызыксынырга, һәрбер комсомолецның, һәрбер яшь эшченең тыл гвардеецы булуына ирешергә тиешләр.

Безнең республикабызда, аерым алганда Казан шәһәрендә, үзләренең эшләрен хәзерге таләпләр югарылыгында оештырган комсомол оешмалары аз түгел.

Менә, ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы иптәш Котова булган заводны алыйк. Биредә һәрбер комсомолец нормасын арттырып үти. Стахановчыларның һәм ударникларның күбесе яшьләр. Комсомолецлар хәрби белемне өйрәнүдә дә алдынгылык күрсәтәләр һәм хәрби укуларга союздан тыш яшьләрне туплыйлар.

Комсомол комитеты секретары иптәш Колесников булган заводта да комсомолецларның, союздан тыш яшьләрнең эшләре сокланырлык. Биредә комсомолец Вәлиәхметов сменасы көнлек заданиене 500—600 процент итеп үти. Бу сменада иң алдынгы токарь Измайлов һәр көнне 8—9 ар норма бирә. Аның үрнәгендә заводның бик күп эшчеләре нормаларын 200—300 процент итеп үтәүгә ирештеләр. Завод эшчеләре батыр сугышчыларга җылы киемнәр җыюда, танклар колоннасы һәм самолетлар эскадрильясы төзелешенә средство туплауда да зур оешканлык үрнәкләре күрсәтәләр. Яшьләр арасында көндәлек политик-тәрбия эшләре алып барылган һәм аларга большевистик җитәкчелек булган урыннарда эш әнә шулай тора.

Ләкин Казан шәһәре комсомол оешмалары барысы да үзләренең эшләрен ватан сугышы таләп иткәнчә оештырдылар дип әйтеп булмый әле. Күп кенә башлангыч комсомол оешмаларының эшләрендә җитди кимчелекләр бар. Беренче тегү, Микоян исемендәге, Кетгут, «Спартак» һәм башка кайбер завод-фабрикалар янындагы комсомол оешмаларының эшләре гафу ителмәслек начар куелган. Бу оешмалар комсомол сафларын үстерү мәсьәләсе белән җитәрлек шөгыльләнмиләр. Яшьләр арасында социалистик ярыш тиешенчә оештырылмаган һәм аңа җитәкчелек җитәрлек түгел. Күп кенә уку йортлары янындагы комсомол оешмаларының эшенә карата да шуны әйтергә мөмкин. ВЛКСМ ның Казан шәһәр комитеты исә мондый оешмаларның эшенә конкрет җитәкчелекне тәэмин итмәде, аларның эшләренә конкрет булышлык оештырмады.

Комсомолның Казан шәһәр комитетының практик эшендә җитди кимчелекләр яшәп килә. Барыннан да элек, комсомол сафларын үстерүнең канәгатьләнерлек булмавын әйтергә кирәк. Казан шәһәр предприятиеләрендә эшләүче яшьләр арасыннан 1942 нче елда бары 6.619 гына кешенең комсомол сафларына алынуы моны ачык күрсәтә.

Комсомолның Казан шәһәр оешмалары үзләренең эшләрен ватан сугышы таләп иткәнчә яңа баштан корырга тиешләр. Алар яшьләрне илебез алдында торган бөек бурычларны үтәүгә тупларга, яшьләр арасында политик-тәрбия эшләрен тагын да көчәйтергә тиешләр.

Бүген, 14 нче мартта, ВЛКСМ ның Казан шәһәр оешмасының VI нчы конференциясе ачыла. Конференциядә комсомол шәһәр комитетының отчет чорындагы эше турында доклад тыңланачак. Конференция шәһәр комитетының эшендә булган кимчелекләрне ачып салырга, комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында эшне яхшыртуга юнәлдерелгән конкрет чаралар билгеләп калдырырга тиеш. Комсомол, бөек большевиклар партиясенең турылыклы алмашчысы буларак, ватан сугышы шартларында үз алдына куелган бурычларны намус белән үтәр.

Партия оешмаларының бурычы исә, комсомолга җитәкчелекне күп тапкыр көчәйтүдән гыйбарәт.

Совет Информбюросыннан

13 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Вязьмадан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер участокта дошман, көчле итеп ныгытылган терәк пунктларга таянып, совет частьларының алга баруларын тоткарларга маташты. Безнең сугышчылар немецларның оборона линиясен әйләнеп үттеләр һәм гитлерчылар, чолганып алынудан куркып, тәртипсез рәвештә чигенделәр. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәләре һәм дошман тарафыннан ташлап калдырылган күп кенә кораллар калды.

Каменка авылында өлкән лейтенант Тесля командалыгындагы безнең бер рота автоматчикларыбыз немецлар тарафыннан тирә-як авыллардан куып китерелгән 1.500 совет гражданын азат иттеләр. Гитлерчылар бу кешеләрне юк итмәкче булганнар һәм инде аларны атарга да керешкәннәр. Совет автоматчиклары, немец бандитларга кинәт атака ясап, колхозчыларны котылгысыз үлемнән коткарып калдылар.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр, немецларның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар.

Лейтенант Петров командалыгындагы безнең разведчиклар отряды дошманның бер складын кулга төшерде. Бу складта 6 авыр орудие, берничә дистә пулемет, күп кенә снаряд, патрон запаслары һәм төрле сугыш милекләре бар иде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның атакаларын кире кайтарып, бик каты сугышлар алып бардылар. Гитлерчылар, гаять күп кешеләрен һәм техникаларын югалтуга да карамастан, шәһәргә таба ыргылуларын дәвам иттерәләр. Н-че берләшмә частьлары сугышларның ике көне эчендә немецларның 46 танкысын, 100 дән артык автомашинасын һәм берничә мең гитлерчыны юк иттеләр. Харьковтан көньяктарак Н-че берләшмә сугышчылары немецларның 11 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар, 300 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды, засадалардан торып, 50 гә якын немец солдатларын юк иткән һәм немецларның бер хәрби эшелонын һәлак итүне оештырган. Икенче бер отрядның партизаннары дошманның фронт линиясенә бара торган бер поездын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган.

* * *

Бик каты сугышлардан соң кичә безнең гаскәрләр Вязьма шәһәрен алдылар.

Оккупация чорында һәм чигенер алдыннан немецлар шәһәрне талаганнар һәм юкка чыгарганнар. Гитлерчылар барлык совет авылларында һәм шәһәрләрендә ачыктан-ачык юлбасарлык һәм талау үткәрделәр һәм үткәрәләр. Вязьмада алар бигрәк тә котырынганнар. Немец бандитлар шәһәрнең барлык культура учреждениеләрен һәм тарихи памятникларын талаганнар һәм юк иткәннәр. Фашист варварлар Вязьманың драма театрын, шәһәр кино-театрын, Вязьма музеен, укытучылар институтын, культура йортын, тимер юлчылар клубын, пионерлар йортын, шәһәр больницасын талаганнар һәм җимергәннәр. XVIII нче гасырның беренче яртысында салынган борынгы биналар җимерекләр өеменә әйләндерелгән. Немец-фашист басып алучылар Вязьманың кафедральный соборын да җимергәннәр.

* * *

Миниште районында Югославия партизаннары немецларны зур югалтуларга дучар иткәннәр. Бу районда оккупантларга каршы сугышларда Югославия патриотлары соңгы вакытларда 200 гә якын гитлерчыны кырганнар. Седло һәм Мали Лог якынында 138 итальян солдаты һәм офицеры юк ителгән. Партизаннар итальян оккупантларның 40 пулеметын һәм күп кенә сугыш припасларын кулга төшергәннәр.

13 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

12 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 10 танкысын һәм бронемашинасын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар, 2 ягулык складын һәм бер сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Вязьмадан көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган бик күп пунктларны, шул исәптән Угра тимер юл станциясен алдылар. Дошман каты каршылык күрсәтә, ләкин безнең частьларның кискен ударлары белән үзенең оборона чикләреннән алып ташлана. Халык яши торган бер пункт районында немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәләре калды. 6 орудие, 27 пулемет, 9 миномет һәм бик күп сугыш припаслары кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Харьков районында бик каты сугышлар дәвам итте. Шәһәрдән көнбатыштарак дошманның бик күп танклары һәм пехотасы, күп тапкырлар атака ясаганнан соң, авыр югалтулар исәбенә безнең частьларны бераз кысрыклый алдылар. Безнең гаскәрләр, яңа чикләргә урнашып, сан ягыннан өстен булган дошман көчләренең басымын тоткарладылар, гитлерчыларның атакаларын кире кайтардылар һәм аларны гаять зур югалтуларга дучар иттеләр. Шулай ук шәһәрдән төньяктарак немецларның бик күп танклары һәм мотопехотасы атакалар алып бардылар. Бу участокта бик каты сугышлар дәвам итә. Харьковтан көньяктарак дошманның бер полк пехотасы һәм берничә дистә танкысы берничә тапкыр һөҗүмгә күчте. 11 танкларын һәм 500 гә якын солдат һәм офицерларын югалтканнан соң, гитлерчылар элекке позицияләренә чигенделәр.

* * *

Изюм районында безнең частьлар дошманның берничә атакасын кире кайтардылар һәм немецларның 6 танкысын, 200 дән артык гитлерчыны юк иттеләр. Бер участокта дошманның бер группа автоматчиклары безнең гаскәрләр урнашкан урынга үтеп чыккан иде. Н-че часть сугышчылары немец автоматчикларының бу группасын чолгап алдылар һәм юк иттеләр.

Безнең очучылар һава сугышларында дошманның 9 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче «За родину» исемле партизаннар отряды 100 дән артык гитлерчыны кырып ташлаган. Щорс исемендәге отрядның партизаннары тимер юлга миналар куйганнар. Партизаннар куйган миналарга бәрелеп, дошманның 2 паровозы һәм сугыш припаслары төялгән 10 вагоны шартлаган. Тимер юлның бу участогында поездлар йөреше тукталган. Шул ук отрядның бер группа партизаннары кинәт бер тимер юл станциясенә һөҗүм иткәннәр. Совет патриотлары часовойларны үтереп, немецлар казармасына бәреп кергәннәр. Каршылык күрсәтергә маташкан сакчы солдатлар үтерелгән. Калган 25 солдат һәм бер офицер пленга бирелгән. Кораллар һәм сугыш припаслары кулга төшерелгән.

* * *

Немецларның 299 нчы пехота дивизиясенең 529 нчы полкыннан плен алынган солдат Эрих Грунек болай диде: «Сәламәтлегем начар булганлыктан мине строй хезмәтенә яраксыз дип таптылар һәм марш батальоннарын фронтка озатучы командага җибәрделәр. Соңгы вакытларда марш батальоннарының берсе дә билгеләнгән урынга тулы состав белән килгәне юк. Юлда һәрбер эшелоннан дистәләгән солдатлар качтылар. Январь аенда жандармерия Киевта һәм аның тирәләрендә берничә облава үткәрде. Бер ай эчендә генә дә меңнән артык дезертир тотылды һәм судка бирелде».

* * *

Калинин өлкәсенең немецлардан азат ителгән Линея авылында торучылар түбәндәге актны төзеделәр: «Гитлерчы юлбасарлар басып кергәнчегә кадәр безнең авылда барлык крестьяннар таза тормышта яшиләр иде. Һәрбер колхозчының сыеры, сарыклары һәм йорт кошлары бар иде. Хәзер авылда бер сыер да, бер сарык та, бер дуңгыз баласы да, бер тавык та юк. Бөтенесен немец бандитлар талап бетерде. Алар халыкның бөтен азыкларын талап алдылар һәм халыкны ачлыктан үлүгә дучар иттеләр. Немец солдатлары безнең авылдашыбызны — Александр Цветковны кыйнадылар. Ул алар турында немецлар комендантына зарланды. Фашист ерткыч аның зарлануын тыңлап торганнан соң, шунда ук Цветковны атып үтерергә приказ биргән. Күрше Громовка авылында фашист ерткычлар 200 дән артык кешене, шул исәптән хатын-кызларны һәм балаларны газаплап һәм атып үтерделәр». Актка Мария Попова, Михаил Цевельков, Александр Попов һәм башкалар кул куйган.

Азат ителгәннән соң үткән бер ай

Ростовны немец-фашист басып алучылардан азат итүгә бер ай тулып үтте. Бу вакыт эчендә шәһәр танымаслык булып үзгәрде.

Шәһәр халкы предприятиеләрне, җәмәгать биналарын, торак йортларны, коммуналь хуҗалыкны бөтен көчен биреп аякка бастыра. Хәзер инде водопровод, почта һәм телеграф, тегерменнәр һәм пекарьнялар эшли башлады. Ашханәләр ачылды.

Күп заводларда һәм фабрикаларда производство юлга салынды. Калинин исемендәге завод комбайннар өчен меңнәрчә запас частьлар эшләп чыгарды. Ростов авыл хуҗалыгы машиналары заводы фронтка кирәкле машиналарга ремонт ясый. «Красный Дон» елга флотын навигациягә әзерли. Микоян исемендәге фабрика беренче партия аяк киемнәрен эшләп чыгарды.

Немецларның җимерүләреннән исән калган 32 мәктәптә 15 мең бала укый башлады. Шәһәрдә музыкаль комедия театры эшкә керешә, ике кино-театр ачылды.

Азовтан, Егорлыкская станицасыннан һәм Александровкадан Ростовка авыл хуҗалыгы продуктлары төялгән обозлар килә.

(ТАСС).

ТЕАТР КОЛЛЕКТИВЛАРЫ КОЛХОЗЛАРГА ЧЫГАЛАР

Язгы чәчү вакытында колхозларга, совхозларга һәм МТС ларга художество хезмәте күрсәтү өчен Сәнгать эшләре комитеты колхозларга һәм совхозларга 300 дән артык театр коллективлары җибәрергә карар бирде. Аларның һәрберсе кимендә 50 спектакль бирәчәк.

ВЛКСМ НЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВЛКСМ ның VI нчы Казан Шәһәр конференциясе 1943 нче елның 14 нче мартында, көндез 12 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта ачыла.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

Промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында

(ДӘВАМЫ).

Халыкара хатын-кызлар көне — 8 нче мартны истә калдыру теләге белән промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларыннан түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләргә:

111. Евдокия Дмитриевна **Зверевалы** — ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге инструкторы.

112. Наталия Васильевна **Зверевалы** — 2 нче номерлы ТЭЦ эшчесе.

113. Зәйтүнә **Җиһаншинаны**—Куйбышев исемендәге фабрика эшчесе.

114. Фатима Зиннур кызы **Зиннуровалы**—14 нче номерлы фабриканың смена начальнигы.

115. Ольга Михайловна **Зуеваны** — Татарстан АССР Җир эшләре Халык комиссариатының өлкән экономисты.

116. Разия Мостафа кызы **Ибраһимованы**—эвакогоспиталь сестрасы.

117. Елена Ивановна **Ивановалы** — ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты инструкторы.

118. Елизавета Васильевна **Ивановалы**— Н-че завод токаре.

119. Мария Федоровна **Ивановалы** — Н-че завод эшчесе.

120. Юлия Алексеевна **Ивановалы**— Казан тимер юлының Әгерже бүлегендәге өлкән стрелкачысы.

121. Нина Ивановна **Ивлиеваны**—Казан мехкомбинаты лаборанткасы.

122. Сания **Именеваны** — Актаныш районы, «Кызыл Сень» колхозының кошлар караучысы.

123. Евдокия Михайловна **Исаеваны** — Алексеевский районы, «Восход» колхозының дуңгыз караучысы.

124. Рәхимә Кәрим кызы **Кадыйрованы**— Чистайның 2 нче номерлы урта мәктәп укытучысы.

125. Лидия Александровна **Казначееваны** — Казан шәһәренең 24 нче номерлы урта мәктәп укытучысы.

126. Камал Хәсән кызы **Кәлимуллинаны**— Н-че завод эшчесе.

127. Клавдия Александровна **Калмыкованы**—ВКП(б) ның Казан шәһәр Комитеты оештыру -инструкторлык бүлеге мөдире.

128. Гөлчирә Мөхәммәтша кызы **Кальметьеваны** — Татарстан АССР Совнаркомының бүлек мөдире.

129. Миңлегөл Насретдин кызы **Камалетдинованы** — Казан энергокомбинаты техникы.

130. Мария Ивановна **Каминецкаяны**— Н-че завод эшчесе.

131. Анна Игнатьевна **Касаткинаны** — Куйбышев исемендәге завод эшчесе.

132. Клавдия Дмитриевна **Кирсанованы**— Серго исемендәге завод эшчесе.

133. Лидия Федоровна **Кирюшинаны** — Ленин исемендәге завод эшчесе.

134. Пелагея Осиповна **Клепиковалы** — Н-че завод эшчесе.

135. Александра Филипповна **Ковалеваны** — Н-че завод эшчесе.

136. Евдокия Ивановна **Кокареваны** — 14 нче номерлы трестның хатын-кызлар бригадасы бригадиры.

137. Фаина Александровна **Колягинаны**— Серго исемендәге завод эшчесе.

138. Ксения Терентьевна **Кондрашеваны**— 14 нче номерлы трест эшчесе.

139. Мәрьям **Коннуринаны** — Казан тимер юлының Казан станциясендәге грузчиклар бригадиры.

140. Пелагея Семеновна **Корнишинаны**— Алексеевский районы, Тельман исемендәге совхозның бозау караучысы.

141. Елизавета **Королеваны** — Чаллы районы, «Татарстан» совхозының тракторчысы.

142. Елизавета Федоровна **Королеваны**— Октябрь районы, Кече Камышлы башлангыч мәктәбе укытучысы.

143. Ксения Афанасьевна **Королеваны**— Куйбышев районы, «КИМ» совхозының бозау караучысы.

144. Зоя Павловна **Корягинаны**—Актаныш районы җир бүлегенең баш ветеринария врачы.

145. Клавдия Александровна **Корчагинаны** — эвакогоспиталь врачы.

146. Мария Николаевна **Косенкованы**— Алабуга районы, «Сентәк» колхозының колхозчысы.

(Дәвамы бар).

НЕМЕЦ-ФАШИСТ КЕШЕ АШАУЧЫЛАРНЫҢ РОСТОВ-ДОНДАГЫ ЕРТКЫЧЛЫКЛАРЫ

Түбәндә немец-фашист кабахәтләрнең Ростов-Донда эшләгән коточкыч ерткычлыклары турында акт һәм фотодокументлар игълан ителә:

АКТ

Без, түбәндә кул куючылар, бу актны шушы турыда төзедек: немецлар Ростовны алганнан соң шәһәр коменданты немец генерал-майоры Киттель шәһәр халкын куплап кыруны оештырды. Күп йөзләрчә гражданнар, үзләренең балаларын, кыйммәтле әйберләрен һәм өч көнлек азык запасы алып, җыелу пунктларына килергә мәҗбүр булдылар. Анда аларны, йөк автомобильләренә утыртып, шәһәр читенә алып киттеләр. Ботаника бакчасы һәм зоопарк районында олы кешеләрне аттылар, ә балаларны иреннәренә бик көчле тәэсир итә торган агулы матдәләр сөртеп, агуладылар. Тулы булмаган саннарга караганда, немец палачлар 15—18 мең кешене атканнар һәм агулаганнар. Атылганнар арасында 2 нче совет больницасының күз авырулары бүлеге мөдире доцент Киршман, терапевт — врач Инал, юрист Луцкий, Ворошилов исемендәге заводның директор урынбасары Буняков һәм аның хатыны, доцент Новиков, аның 70 яшьлек анасы, хатыны һәм 8 яшьлек улы, доктор Шершевская, медицина сестрасы Симанович, токарь Павловская һәм башкалар бар.

Оккупация чорында һәм бигрәк тә шәһәрне калдырып китәр алдыннан немец варварлар Ростовтагы күп кенә промышленность предприятиеләрен таладылар, шартлаттылар һәм яндырдылар. Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы машиналары заводы, «Красный Аксай» заводы, паровозларга ремонт ясый торган Ленин исемендәге завод, «Красная звезда» казлык фабрикасы, «Смычка» консерв заводы, Воровский исемендәге чуен кою заводы, 2 нче номерлы он-макарон комбинаты, Ворошилов исемендәге механика заводы, илебездә иң зур икмәк заводларыннан булган механикалаштырылган икмәк заводы, электро-теплоцентраль, автобус парк ы, трамвай парк ы, бөтен шәһәрдә трамвай һәм троллейбус челтәре, почта һәм телеграф, типографияләр, водопровод, канализация, кино-механика мастерскойлары, төрле азык фабрикалары, комбинатлар, башка төрле зур предприятиеләр һәм корылмалар—болар барысы да җимертелде.

Немец варварлар өлкә дәүләт көтепханәсенең 2 миллионнан артык китабын яндырдылар һәм 25 көтепханәне таладылар. Сирәк табыла торган һәм гаять дәрәҗәдә зур фәнни әһәмияте булган китаплар юк ителделәр яки Германиягә алып киттеләр. Оккупантлар үзәк шәһәр больницасының төп корпусларын, 1 нче, 3 нче һәм 4 нче поликлиникаларны, тимер юлчылар поликлиникасын һәм башкаларны җимерделәр. Кайбер болницалар анда булган авыру кешеләр белән берлектә юк ителделәр. Фашист мародерлар больницалардагы иң кыйммәтле медицина аппаратларын һәм инструментларын Германиягә алып киттеләр.

Варварлар шәһәрдәге иң яхшы җәмәгать биналарын: Советлар Йортын, «Интурист» һәм «Интернационал» гостиницаларын, Горький исемендәге драма театрын, эстрада театрын, яшь тамашачы театрын, музыкаль комедия театрын, «Гигант» һәм «Хроника» кинотеатрларын, мәгариф йортын, Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы машиналары заводының культура сараен, электриклар, медицина санитария работниклары һәм элемтә работниклары профсоюзларының клубларын, тимер юл транспорты инженерлары институтын, Ростов медицина институтының фәнни тикшерену лабораторияләрен һәм клиникаларын, педагогия институтын, Молотов исемендәге университетның физика-математика факультеты бинасын, элемтә техникумын, төзү техникумын, музыка мәктәбен, 50 дән артык урта мәктәпне, Революция музеен, крайны өйрәнү музеен, академик көтепханәне һәм башка шундый биналарны җимерделәр һәм яндырдылар.

Энгельс урамында вокзалдан алып Ворошилов проспектына кадәр булган барлык торак йортлар, Пушкин, Шаумян һәм Социалистический урамнарында вокзалдан алып Буденный проспектына кадәр булган биналарның күп өлеше, шулай ук Буденный, Театральный һәм Ворошилов проспектларында, «Ростсельмаш» поселогында, Олимпиадовкада һәм башка урыннарда биналарның һәм торак йортларның шактый өлеше шартлатылды һәм яндырылды. Горький исемендәге парк Ростов халкының мактанычы иде. Немец варварлар парктагы иң кыйммәтле агачларны кисеп бетерделәр, фонтаннарны һәм павильоннарны җимерделәр.

Җәмәгать биналарын һәм торак йортларны җимерү түбәндәгечә барды: ут төртүче һәм шартлатучы саперлардан төзелгән махсус командалар биналарга миналар куеп, аларны шартлатып тордылар, биналарның шартламый калган өлешләренә бензин сибеп ут төрттеләр. Хәтта бандитлар бу турыда йортларда торучыларга кисәтү ясарга кирәк дип тә санамадылар. Җимерелгән биналар астында калып йөзләрчә кешеләр һәлак булды.

Гитлерчылар ату белән куркытып, Ростовның бик күп кешеләрен Германиягә каторгага озаттылар. Шәһәр коменданты приказы буенча 14 яшьтән 60 ка кадәр булган барлык ирләргә һәм 15 тән 50 яшькә кадәр булган барлык хатын-кызларга регистрация үткәрелде. Аларның паспортларын алдылар. Соңыннан бу кешеләрне җыелу пунктларына чакырып китерделәр. Ату белән куркытып, аларны вагоннарга утырттылар һәм, хәйваннарны алып киткән кебек, көнбатышка озаттылар. Шундый юл белән Германиягә күп меңнәрчә совет кешеләре озатылды. Ростовның калган халкы ачлыктан һәм авырулардан үлүгә дучар ителде.

Кызыл Армиянең ударлары астында чигенгән чакта немец оккупантлар шәһәр төрмәсендә Ростов халкыннан кулга алынган 135 кешене җәзалап үтерделәр. Аларны үтерер алдыннан палачлар үзләренең корбаннарын коточкыч төстә газапладылар—борыннарын кисеп алдылар, күзләрен чытардылар, аякларын һәм кулларын кистеләр. Шуннан соң гитлерчылар төрмә бинасын һәм анда ябылган совет гражданнарын шартлаттылар. Төрмә ишек алдында 1.154 кешенең, шул исәптән 122 хатын-кызның һәм 57 баланың үле гәүдәләре табылды. Төрмәдә атып һәм газаплап үтерелгән кешеләр арасыннан инженер Георгий Ждановны, эшче Анна Михайлованы һәм башка кайберәүләрне танырга мөмкин булды.

Ростовның совет гражданнары каны белән юылган урамнарында һәм мәйданнарында немец-фашист кабахәтләр эшләгән коточкыч җинаятьләрнең эзләре бар.

Совет халкына, безнең культурабызга, русларныкы булган бөтен нәрсәгә ерткыч ачу белән тулган гитлерчылар шәһәрнең күп елларча яшәве чорында рус халкы төзегән бөтен нәрсәне һәм 25 ел буена совет кешеләре төзегән барлык нәрсәләрне җимерделәр. Бу җимерүләр хәрби карашлардан караганда һич тә кирәк түгел иде.

Безнең туганнарыбызның каны үч алырга чакыра. Ростов-Дон шәһәренең барлык гражданнары исеменнән без барлык эшәке һәм кабахәт җинаятьләр өчен бандитлардан рәхимсез үч алуны таләп итәбез.

Актка кул куйдылар: хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты председателе хезмәтләрен үтәүче **С. Бурменский**, «Заря» сыра заводы инженеры **И. Звезек**, профессор **Н. Стасевич**, профессор **В. Карницкий**, майор **Я Донской**, майор **Д. Седов**, капитан **А. Токарь**, «Метиз» артеле эшчесе **А. Дибров**, «Новый городок» поселогы уполномоченные **А. И. Максева**, Лензавод мастеры **В. Бочаров**, Микоян исемендәге фабриканың техникы **С. Токарев**.

Немецларның Ростов-Донда эшләгән канлы җинаятьләре, алар әле совет халкын кыру буенча, вакытлыча үзләре басып алган районнардагы барлык материаль һәм культура кыйммәтләрен җимерү буенча гитлерчылар үткәрә торган коточкыч программаның кечкенә бер өлеше генә. Немецлар үзләре басып алган барлык совет шәһәрләрен һәм авылларын җимерәләр, Советлар Союзы халыкларының культура һәм тарихи хәзинәләрен талыйлар һәм юк итәләр. Гитлерчылар гражданнар халкын газаплыйлар, атып үтерәләр һәм асалар, хәтта ярдәмчесез хатын-кызларны һәм балаларны үтерүдән дә тукталып тормыйлар. Алар совет гражданнарын ирексезләп Германиягә каторгага алып китәләр, аларны концентрация лагерьларына ябалар һәм котылгысыз рәвештә ачлыктан, кыйналудан һәм авыр хезмәттән үлеп бетүгә дучар итәләр.

Югарыда игълан ителгән акт немец-фашист кабахәтләр тарафыннан үзләре басып алган илләрдә һәм өлкәләрдә урнаштырыла торган «яңа тәртип» не ачык итеп күз алдына китерә. Гитлер солдаты аяк баскан урында һәртөрле культура тормышы сүнә, кыргыйлык һәм җимереклек башлана.

Безнең илебезгә басып кергән, совет җирен кан белән күмүче немец кабахәтләр бөтенесе өчен—гаепсез кешеләрне газаплаулары өчен, хатын-кызларны һәм балаларны үтергән өчен, барлык көчләүләр өчен, талаулар һәм җимерүләр өчен җавап бирерләр. Үч алу сәгате якын!

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

(Фотодокументлар үзәк матбугатта басылып чыктылар).

КОМСОМОЛ ТОРМЫШЫ

ЛАЕКЛЫ КАДРЛАР БУЛЫП ЧЫГАЛАР

Безнең партиябез, хөкүмәтебез, һәрвакыттагы шикелле үк, ватан сугышы шартларында да, югары уку йортларының эшенә, кадрлар әзерләүгә зур әһәмият бирәләр. Партиябезнең, хөкүмәтебезнең бу игътибары, кайгыртучанлык күрсәтүләре һәрбер совет студенты өстенә зур җаваплылык, армый-талмый фәнне үзләштерү һәм җәмәгать тормышында актив катнашу бурычын йөкли.

В. И. Ульянов (Ленин) исемендәге Казан дәүләт университеты комсомолецлары, студентлары моны яхшы аңлыйлар. Алар, отлично һәм яхшы билгеләренә генә уку өчен көрәшәләр. Җәмәгать тормышында актив катнашалар. Кышкы сынаулар сессиясенең нәтиҗәләре моны ачык күрсәтте. Бу сынауларга партия һәм комсомол оешмалары, университет дирекциясе белән берлектә, зур әзерлек эше алып бардылар. Лекцияләр, консультацияләр, семинарлар, теоретик конференцияләр һәм башка фәнни-тикшерену чаралары үткәрелде.

Нәтиҗәдә, сынауларны студентларның дүрттән бер өлеше отлично һәм яртысыннан күбрәге отлично һәм яхшы билгеләренә генә тапшырдылар.

Бу сынауларда комсомолецлар аеруча алдынгылык күрсәттеләр. Бик күп комсомолецлар барлык фәннәрне отлично һәм яхшы билгеләренә генә тапшырдылар.

Иптәш Сталинның 23 нче февраль приказына җавап итеп комсомолецлар, гомумән, студентлар коллективы, тагын да зур энергия белән тырышып укый башладылар. Физика-математика факультетының өченче курс комсомолецлары, студентлары инициативасы белән, иң яхшы курс, иң яхшы группа өчен башланып киткән социалистик ярышка барлык укучылар да кушылдылар. Бу ярышның төп пунктлары итеп, язгы сынауны барлык фәннәр буенча отлично һәм яхшы билгеләренә генә тапшыру, хәрби белемне яхшы итеп үзләштерү һәм аның буенча сынауларны отлично билгесенә генә тапшыру һ. б. пунктлар алынды.

Һәрбер комсомолец, һәрбер студент бер теләк белән—яхшы белемле, ватанга лаеклы кадр булып чыгу, аңа армый-талмый хезмәт итү теләге белән яна.

ЕМЕЛЬЯНОВ,

КДУ ның комсомол комитеты секретаре.

ВЛКСМ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты шушы елның 9 нчы мартында булган бюро утырышында комсмол һәм пионер оешмаларының бәрәңге кисентесе җыю буенча канәгатьләнерлек эшләмәүләрен күрсәтте. Биләр, Чепья, Тәтеш, Сарман, Кайбыч һәм башка кайбер районнарда бәрәңге кисентесе җыю бары 1—2 процентка гына үтәлгән.

Бюро комсомолның район һәм шәһәр райкомнарын, башлангыч оешмаларны һәм МТС, совхоз, политбүлек начальникларының комсомол эше буенча ярдәмчеләрен бәрәңге кисентесе җыю эшен көчәйтергә мәҗбүр итте, бәрәңге кисентесе җыю планының үтәлешен тикшерү өчен 20 нче мартка кадәр рейд үткәрергә һәм бу эшнең барышы турында һәр айның 15 нче һәм 20 нче числоларына ВЛКСМ Өлкә Комитетына хәбәр итеп торырга кушты.

Шулай ук, ВЛКСМ ның Өлкә Комитеты комсомол оешмаларын һәм барлык комсомолецларны, яшьләрне язгы чәчүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча үткәрелә торган фронт айлыгына актив катнашырга чакырды.

КОЛХОЗЧЫЛАР ҺӘМ КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАР, СОВХОЗ, МТС ҺӘМ МТМ ЭШЧЕЛӘРЕ! НЕМЕЦ ОККУПАНТЛАРЫН ТАР-МАР ИТҮДӘ КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ БУЛЫШЛЫК ИТҮНЕ КӨННӘН-КӨН КӨЧӘЙТЕГЕЗ, ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕ ТУЛЫ ӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН КАРШЫ АЛЫГЫЗ!

Скорняк-тегү фабрикасында. Рәсемдә: көнлек норманы системалы рәвештә 200 процент һәм аннан артык үтәп баручы стахановчы иптәш Г. Шәфиков.

С. Парфенов фотосы.

Сугышчан әзерлек белән

ЧИСТАЙ, 13 март. (Телефон буенча). Явыз дошманга каршы безнең Кызыл Армиябез героик сугыш алып бара. Ул йөзләрчә авылларны һәм уннарча шәһәрләрне азат итеп, көннән-көн алга баруында дәвам итә. Кызыл Армиябезнең уңышларына без чиксез шатланабыз. Бу уңышлар бездән илебезгә һәм фронтка ит, сөт, май һәм башка авыл хуҗалыгы продуктларын тагын да күбрәк житештерүне таләп итә.

Безнең «Бахта» колхозы члennары үзләренең саклык акчаларыннан танклар төзү фондына 153 мең сум һәм самолетлар эскадрильясы төзүгә 64 мең сум акча тапшырдылар.

Колхозыбыз дәүләткә ашлык тапшыру буенча 1942 нче елгы заданиене алдынгы колхозлар белән бер вакытта үтәде. Шуның өстенә Кызыл Армия фондына 2.640 пот ашлык һәм 30 центнер ит тапшырды.

Хәзер без немец оккупантларыннан азат ителгән районнарга ярдәм итүне оештырабыз. Колхозчылар бу чараны алкышлап каршы алдылар һәм азат ителгән колхозларда фермалар оештыру өчен 10 сарык, 5 дуңгыз, 3 бозау бирделәр. Шулай ук ашлыклата ярдәм итүчеләр дә бар.

Без быел сугыш чорында икенче язгы чәчүне үткәрәчәкбез. Ә язгы чәчүне уңышлы итеп үткәрүнең югары итеп уңышы алуда нигез икәнен без бик яхшы аңлыйбыз. Язгы чәчү мәйданына тулысынча житәрлек күләмдә орлыклар әзерләп куйдык. Аларның саклануын һәм тишелеп чыгу дәрәҗәләрен һәрвакыт тикшереп торабыз. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны да күптән тәгалләдек. Барлык сбруйларыбыз да төзек һәм житәрлек.

Быелгы язгы чәчүне һәрьяктан яхшы әзерлек белән каршы алачагыбызга һәм аны тик отлично билгесенә генә үткәрәчәгебезгә ышанабыз.

И. Р. СМИРНОВ,
«Бахта» колхозы председателе.

Хуҗаларча кайгыртучанлык нәтиҗәсе

Без Микоян исемендәге колхозда (Шөгер районы), язгы чәчү вакытында кирәкле инвентарьларның һәм сбруйларның әзерлеген тикшердек. Болар турында колхозда хуҗаларча кайгыртучанлык күренеп тора.

Көзге кыр эшләре бетү белән барлык машиналар һәм инвентарьлар өсте ябулы урыннарга җыеп куелган. «Вак-төякләр» дән алып зурларына кадәр барлык сбруйлар һәрберсе дә аерым рәвештә бикле урында саклана. Алар аерым кеше җаваплылыгына тапшырылганнар.

Колхозда язгы чәчүгә кирәкле булган 7 чәчкечкә, 36 сабанга, 30 пар тырмага ремонт ясау күптән төгәлләнгән. Ремонтның сыйфаты яхшы. Язгы кыр эшләренә 70 баш ат катнашырга тиеш. Аларны җигү өчен камыт, дилбегә, постромка баулары, валек кебек кирәкле нәрсәләр житәрлек әзерләнгән. Икенче бригада бригадиры Шәмсенур иптәш Җиһангированың сбруйлар турындагы кайгыртучанлыгын аеруча күрсәтергә кирәк. Бригададагы атларны кыр эшләрендә тулысынча файдалану өчен 35 сабан камыты, 35 пар постромка кирәк. Иптәш Җиһангирова аларны 40 комплект итеп әзерләгән. Шуның өстенә 20 пар иске постромка бауларына ремонт ясалган. Бу әйберләрне житештерүдә бригаданың шорникы иптәш Хәсәновның да тырышлыгы зур.

Шуның белән бергә Микоян исемендәге колхозда язгы чәчүгә әзерлектә кимчелекләр дә бар. Атларны тәрбияләү канәгатьләнерлек түгел. Атлар ат карауучыларга беркетелмәгән. Буаз биәләр һәм түбән көрлектәге атлар аерым тәрбиягә куелмаган. Ат карауучыларга хезмәт көне атларның көрлегенә карап язылмый.

Хәбәрчеләр: **Т. ФӘЙЗЕТДИНОВА, М. МОТАЛЛАПОВА, Ш. ВӘЛИЕВА, Л. РОМАНОВ.**

ЭШЛЕКЛЕ ҖАВАП

Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинның Татарстан АССР хезмәт ияләренә җибәргән котлау телеграммасы Тәкәнеш районы колхозчыларында яңадан гаять зур рухлану тудырды. Бу уңай белән үткәрелгән митингларда колхозчылар Кызыл Армиябезгә ярдәм итүне тагын да көчәйтергә сүз бирделәр, язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп әзерләнү һәм аны иң кыска срокларда үткәрүне тәэмин итү өчен конкрет йөкләмәләр алалар.

Соңгы көннәрдә районда язгы чәчүгә әзерлек эшләре шактый көчәйде. Колхозлар орлык туплауны һәм аларны тиешле кондициягә җиткерүне тизрәк тәмамлау өчен тырышалар. Җитешми торган орлыкларны туплауда колхозчылар колхозларга булышалар.

Мәсәлән, Түбән Арбаш авылы, «Яңа көч» колхозы члены Зәйтүнә иптәш Тажиева колхозга бер гектарлык кәбестә орлыгы бирергә йөкләмә алды. «26 Баку комиссары» колхозы председателе иптәш Закиров колхозга 40 пот бәрәңге орлыгы, «Коммунар» колхозы хисапчысы иптәш Павлов 2 центнер арпа орлыгы, «Кызыл юл» колхозы председателе иптәш Җәләлиев 40 пот бәрәңге орлыгы, «Путь Ленина» члены иптәш Еланьев 2 центнер арпа бирәләр.

Районыбызның күп колхозлары 1943 нче ел задание исәбенә дәүләткә ашлык тапшыру эшенә керештеләр. Бу эштә дә колхозчылар колхозларга булышалар. «Новая жизнь» колхозы члennары моның өчен колхозга 67 центнер, «Ударник» колхозы члennары 107 центнер, «Первая пятилетка» колхозы члennары 92 центнер ашлык бирделәр инде.

Н. ВАФИН,
ВКП(б) райкомы секретаре.

Һәрбер мәктәпкә җир участогы

Мәктәпләрдә укуларның сыйфатын күтәрүдә, укучыларда коллективизм рухын тәрбияләүдә, балалар өчен кайнар аш оештыруның гаять зур роль уйнаганлыгы билгеле. Ләкин безнең күпчелек мәктәпләребездә бу эшне оештыру өчен нык база тудыруга хәзергә кадәр житәрлек игътибар бирелмәде. Һәрбер мәктәп коллективы бу житешсезлекне бетерүгә киечкмәстән керешергә тиеш.

Район күләмендәге җыелышта бу мәсьәләне нык тикшергәннән соң, Әтнә районы укытучылары киләсе уку елында һәрбер мәктәпне, үзенең хуҗалыгында житештерелгән продукция белән тәэмин итү бурычын хәл итәргә карар бирделәр. Бу бурычны үтәү өчен түбәндәге конкрет йөкләмәләрне алдылар.

1. 1943 нче елның язында һәрбер мәктәп каршында—башлангыч мәктәпләр өчен кимендә ике гектардан, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләр өчен кимендә 5 гектардан торган мәктәп участокларын булдыруга ирешергә, бу мәсьәләне тиз арада колхозларның гомуми җыелышында рәсмиләштерергә.

2. Мәктәп участоклары өчен кирәк булган орлыклык материалларны тулысынча әзерләүгә һәм аларны тулы кондициягә китерүгә ирешергә.

3. Билгеләнгән участокларда югары уңыш алуны тәэмин итү өчен агротехниканың барлык чараларын үткәрүгә (тирес чыгару, көл җыйнау һ. б.) керешергә.

4. Һәрбер мәктәп янында йорт куяннары асраучылык булдырырга, моның өчен хәзердән үк кирәкле санда клеткалар ясауга керешергә һәм, 1943 нче елның май аеннан да соңга калмыйча, йорт куяннары булдыруга ирешергә.

5. Язгы-җәйге көннәр башлануга участокларда үсемлекләрне тәрбияләү эшен оештыру белән бергәттән, һәрбер мәктәп янында яшелчәләр саклау урыны булдыруга керешергә.

Әтнә районы укытучылары, бу эшләрне тулысынча үтәп чыгуда үзләренә йөкләнгән бурычларның гаять җаваплы һәм бик кирәкле эш икәнлеген аңлаган хәлдә, Татарстан АССР ның барлык мәктәпләрен һәм укытучыларын бу мактаулы хәрәкәткә кушылырга чакырып мөрәҗәгать иттеләр.

* * *

Һәрбер мәктәп янында җир участогы булдыру, бигрәк тә хәзерге шартларда, политик-хуҗалык яктан гаять зур һәм әһәмиятле мәсьәлә. Әтнә районы укытучыларының бу инициативаларын республикабызның барлык мәктәп коллективлары эләктереп алырга, район мәгариф бүлекләре һәм Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты мәктәп участоклары оештыру эшенә якыннан җитәкчелек итәргә тиешләр. 1943 нче елда һәрбер мәктәп, үзенең җир участогын булдырып, аннан югары уңыш алуга ирешсен.

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННРАГА ЯРДӘМ

Яхшы инициатива

АПАС, (Махсус хәбәрчебездән, телефон буенча). Кызыл Армия көн саен уннарча авылларны һәм әһәмиятле пунктларны немец оккупантларыннан азат итә. Немец-фашист бандитлар тарафыннан ач-ялангач калдырылган картлар, мәсхәрәләнгән аналар, газапланган, ятим калдырылган балалар үзләренең туып үскән илләрендә яшәргә мөмкинлек алдылар. Ләкин аларның тораклары, мал-туарлары туздырылган, кием-салымнары таланган. Азат ителгән районнардагы безнең туганнарыбыз җитди ярдәмгә мохтаҗ һәм без ул ярдәмне күрсәтергә тиешбез.

Апас районының колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары моны бик яхшы аңлыйлар һәм аларга ярдәм кулларын сузалар.

Киров исемендәге колхоз члennары азат ителгән өлкәләрдәге колхозларның ярдәм фондына 3 тана, Энгельс исемендәге колхоз члennары 3 сарык һәм бер тана бирергә карар чыгардылар.

Бу хәрәкәт башка колхозларда да җәелеп бара. Хәзер Сталинград өлкәсендәге бер колхозга бүләк итү өчен 50 сарык һәм 25 сыердан торган ферма оештырылды.

Укучы балалар да ата-аналарыннан калышмыйлар. Мәктәп балалары азат ителгән өлкәләрнең авылларындагы мәктәпләре өчен уку-укыту әсбаплары җыя башладылар.

Яхшы инициативага—киң юл!

М. НУРЕТДИНОВА.

СВОДКА.

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 10 нчы МАРТЫНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	38. Кукмара	78,8	75. Ютазы	60,0
2. Чокалы	100,0	39. Кузайкино	78,2	76. Питрәч	59,6
3. Актаныш	100,0	40. Бондюг	77,8	77. Мөслим (Чистай)	58,8
4. Бөгелмә	100,0	41. Кызыл йолдыз	77,8	78. Биләр	58,7
5. Нөркәй	100,0	42. Димитров	77,1	79. Константиновка	57,7
6. Алга	100,0	43. Мәлки	76,0	80. Казанбаш	57,6
7. Тымытык	100,0	44. Поповка	75,6	81. Ромадан	57,4
8. Алабуга	100,0	45. Калинин	75,6	82. Столбище	57,4
9. Тирсә	100,0	46. Балтач	75,0	83. Иске Чишмә	56,8
10. Ишеево	100,0	47. Аксубай	75,0	84. К. Тамагы	56,7
11. Чүпрәле	100,0	48. Кызыл Чапчак	75,0	85. Зур Поляна	56,1
12. Дөбьяз	100,0	49. Яңа Чишмә	74,5	86. Салман	55,3
13. Яниль	100,0	50. Баулы	74,1	87. Мәйдан	55,2
14. Саба	96,0	51. Куйбышев	73,7	88. Әхмәмәт	54,9
15. Мөрәле	95,0	52. Шөгер	71,7	89. Карамалы	54,5
16. Зөя	95,3	53. Тәтеш	70,8	90. Әлки	53,6
17. Юртыш	92,9	54. Кичү	69,0	91. Кызыл юл	53,3
18. Кадряк	91,9	55. Кәкре елга	68,9	92. Макыл	52,8
19. Октябрь	91,4	56. Тельман	68,9	93. Минзәлә	52,1
20. Юдино	90,0	57. Буденный	68,4	94. Б. Бистәсе	52,0
21. Т. Тамак	89,7	58. Әтнә	68,0	95. Үзәк	50,0
22. Чүрибураш	89,4	59. Теләче	67,3	96. Трехозерский	49,1
23. Сарман	88,7	60. Әлмәт	66,7	97. Т. Ялтан	48,5
24. Олы Кариле	88,0	61. Буа	66,7	98. Мамадыш	48,4
25. Дәүләки	87,0	62. Беренче Май	86,7	99. Ключи	44,8
26. Исәнбай	86,5	63. Черемуховский	64,8	100. Кузнечиха	44,4
27. Заинский	86,2	64. Морт	64,7	101. Чиябаш	44,4
28. Соколка	84,4	65. Әлши	64,3	102. Иске Писмән	43,3
29. Чистай	84,4	66. Рождественский	64,1	103. Тат. Ходяш	41,7
30. Тархан	83,6	67. Каргалы	63,3	104. Биектау	41,7
31. Норлат	83,3	68. Тәкәнеш	62,3	105. Чишмә	39,4
32. Акташ	82,8	69. Чаллы	62,2	106. Кошкино	30,4
33. Азин	81,0	70. Маткавыш	62,1	БАРЛЫГЫ:	71,1
34. Иске Тимошкино	80,8	71. Солтан	61,8	1943 нче елның 5 нче мартына	69,4
35. Б. Матак	80,4	72. Зирекле	61,5		
36. Чаллы	80,0	73. Алексеевский	60,9		
37. Чыбыклы	80,0	74. Арча	60,5		

Директоры иптәш Виземан булган 14 нче номерлы фабрика производство калдыкларыннан киң куллану әйберләре эшләүне оештырды. Сулда — стахановчы В. Михайлова. Ул нормасы 200 процентка үтәп бара. Уртада—моделистлар группасы ассортиментлар үрнәкләрен эшлиләр. Уңда—эшләнгән әйберл әрнең үрнәкләре

С. Парфенов фотосы.

ХАЛЫККА КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮНЕ ТАГЫН ДА КӨЧӘЙТИК!

ФЕВРАЛЬ АЕНЫҢ КАЙБЕР ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА

ҖИРЛЕ ПРОМЫШЛЕННОСТЬ

Февраль ае—хезмәт күтәренкелегенең тагын да үскән ае булды. Кызыл Армиянең җиңүле һөҗүмнәре белән, Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның чакыруы белән рухланган хезмәт ияләре производствода яңадан - яңа уңышларга ирештеләр.

Җирле промышленность предприятиеләре бу айда, башка айлар белән чагыштырганда, шактый яхшы эшләделәр. Районнар буенча валовой продукция планы 145,2 процентка, киң куллану товарлары эшләп чыгару планы 163,2 процентка үтәлде. Ә наркомат буенча 950 мең сумлык урынына 1.545 мең сумлык продукция бирелеп, киң куллану товарлары эшләп чыгару планы 162,6 процентка үтәлде.

Барлык ассортимент буенча планны үтәү—җирле промышленность предприятиеләре өчен бик әһәмиятле. Февраль аенда бу өлкәдә дә шактый уңышларга ирешелде. Төп ассортимент буенча план үтәлде һәм арттырып үтәлде. Мәсәлән, өс киемнәре ремонтлау планы 295 процентка, киез итек басу—268,2 процентка, аяк киемнәре тегү—168,5 процентка, балчыктан савыт-саба — 125,4 процентка, чана—121,4 процентка, кер сабыны—115 процентка, чаңгы—101,8 процентка, арба ясау—101 процентка үтәлде.

Күп кенә урыннарда производство отходларыннан киң куллану товарлары җитештерү өчен яңа цехлар ачылды. Мәсәлән, Чистай галантерея фабрикасында (директоры Борзенков) производство отходларыннан киң рәвештә файдалану оештырылды. Арча райпромкомбинатында (директоры Феоктистов) февраль аенда берничә яңа цех ачылды.

Өч шәһәр ярышы

Кызыл Армиянең 25 еллыгы алдыннан, халык өчен киң куллану товарлары күбрәк җитештерү буенча Казан, Чистай һәм Зеленодольск шәһәрләре үзара социалистик ярышка чыкканнар иде. Бу шәһәрләрнең предприятиеләрендә һәм артельләрендә ярыш киң җәелдерелде. Шуның нәтиҗәсе булarak күпчелек коллективлар йөкләмәләрен тулысынча үтәүгә ирештеләр.

Зеленодольск шәһәре 682.000 сумлык продукция биреп, киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча февраль ае планын 167 процентка үтәде.

Чистай шәһәре киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча айлык планны Кызыл Армия көненә—23 нче февральгә 100,2 процент итеп үтәде. Шәһәр планнан тыш өстәмә рәвештә 500.000 сумлык киң куллану товарлары бирде.

Казан шәһәре предприятиеләре киң куллану товарлары эшләп чыгару планын 98,8 процентка үтәделәр.

Шулай итеп, өч шәһәр ярышында Зеленодольск шәһәре беренче урынны алды.

КАЗАН ПРОМКОМБИНАТЫ

Казан шәһәр промкомбинаты берничә айлардан бирле инде җирле промышленность предприятиеләре арасында беренче урынны алып килә.

Февраль аенда комбинат валовой продукция планын 141,6 процентка, киң куллану товарлары эшләп чыгару планын 171,3 процентка үтәде. Комбинат бу айда 0,935 тонна урынына 2,0 тонна кер сабыны биреп, моның буенча планны 220 процентка үтәп чыкты.

ПРОМКООПЕРАЦИЯ

Бу системада күп кенә артельләр валовой пордукция бирү һәм киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча айлык планнарын үтәп барсалар да, тоташ промсоюзлар үз планнарын бик сирәк үтиләр иде әле. Февраль аенда, Кызыл Армиябезнең 25 еллыгына багышланган социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә, промкооперация системасындагы күпчелек артельләр генә түгел, хәтта тоташ промсоюзлар да айлык планнарын үтәп һәм арттырып үтәп чыктылар. Мәсәлән, Леспромсоюз һәм Пищепромсоюз валовой продукция буенча да, киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча да планны арттырып үтәүгә ирештеләр. Стройтранспромсоюз киң куллану товарларын эшләп чыгару планын 125 процентка, Ремонтпромсоюз 113,2 процентка үтәде.

Киң куллану товарлары һәм көнкүреш әйберләре җитештерү өлкәсендә промкооперация артельләре бу айда аеруча яхшы күрсәткечләргә ирештеләр. Моны хуҗалык әйберләре буенча төп ассортимент планының үтәлүе ачык күрсәтә. Мәсәлән, система производство отходларыннан яңа аяк киемнәре тегү, кер сабыны кайнату, балчыктан савыт-саба, агач кашык, чана, балалар уенчыклары эшләү буенча планны шактый арттырып үтәде. Хуҗалык бавы ишү һәм щетка эшләү, известь чыгару, өс киемнәренә ремонт ясау һәм башка күп кенә ассортиментлар буенча планны система ике тапкырга арттырып үтәде.

Стена газеталары редакторлары өчен курслар

«Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе Ютазы районында чыга торган «Коммунизм» газетасы редакциясе белән берлектә стена газетасы редакторларының 3 көнлек курсын үткәрде. Курска 25 кеше катнашты. Алар арасында ферма мөдирләре, кырчылык бригадалары бригадирлары, колхоз хисапчылары һәм уку өе мөдирләре бар. Курсантлар лекцияләрне зур кызыксыну белән тыңладылар. Алар мондый курсларны ешрак үткәрү кирәклеген әйттеләр.

Курсантлар белән практик эш тәртибендә «Кызыл елга» һәм Ворошилов исемендәге колхозларда язгы чәчүгә әзерлекнең торышын тикшерү буенча рейд үткәрелде. Рейд яхшы нәтиҗәләр бирде һәм бу колхозларда язгы чәчүгә әзерлектә күп кенә кимчелекләрне ачты.

А. ВӘЛИЕВ.

ГАЗЕТАДА БАСЫЛМАГАН ХАТЛАР ЭЗЕННӘН

Азнакай районы, Кәкре елга МТС ының өлкән агрономы—хәзерге вакытта Хәрәкәттәге Армиядә хезмәт итүче иптәш Тимербулатов шушы көннәрдә «Кызыл Татарстан» редакциясенә хат җибәрде. Иптәш Тимербулатов үзенең хатында МТС җитәкчеләренең аның семьясына—хатыны һәм кече яшьтәге ике баласына бер төрле дә ярдәм күрсәтмәүләре турында язган иде.

Азнакай районы прокуроры иптәш Минникаевның катнашы белән бу факт урында тикшерелде. Иптәш Тимербулатовның семьясына МТС тан квартира бирелде. Хатыны пикарьняга эшкә урнаштырылды.

* * *

Чүпрәле районындагы «Марс» колхозы председателе Волковның үз эшенә салкын каравы һәм системалы рәвештә эчүчелек белән шөгыльләнүе турында редакциягә алынган хат район советы башкарма комитеты тарафыннан тикшерелде. Хәбәрче тарафыннан күрсәтелгән фактлар тулысынча расландылар. Колхозчыларның гомуми җыелышы Волковны эшеннән алды.

СУД

РЕМОНТ ЭШЕНӘ САБОТАЖ ЯСАГАН ӨЧЕН

Питрәч районының Тат. Ходяш МТС ында трактор бригадасы бригадиры Гыйльми Мифтахов хезмәт дисциплинасын системалы рәвештә бозып килгән. Узган көз көнендә ул ике тракторны кырда ташлап калдырган.

Ремонт вакыты килеп җиткәч, МТС дирекциясе Мифтаховка үзенең бригада членнары белән берлектә тракторларны төзәтергә кушкан, ләкин Мифтахов, төрле сылтаулар табып, атналар буена эшкә килмәгән. Ниһаять, ремонт эшеннән бөтенләй баш тарткан. Бу хәл ремонт буенча өзеклектә килгән Тат. Ходяш МТС ында эшнең тагын да начарлануына китергән. Бу МТС, тракторларга ремонт ясауда, Татарстан МТС лары арасында иң арттa баручыларның берсе булып тора.

Эшкә саботаж ясаучы Мифтаховның эше шушы көннәрдә Татарстан Верховный судының күчмә сессиясендә каралды. Мифтахов 5 елга төрмәгә ябылуга һәм җәза срогын тутырганнан соң сайлау,-сайлану хокукыннан 3 елга мәхрүм ителүгә хөкем ителде.

Англия бомбардировщикларының Штутгартка һөҗүме

ЛОНДОН, 12 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә игълан ителүенчә, 12 нче мартка каршы төндә Англия бомбардировщиклары Көньяк-Көнбатыш Германиядә иң әһәмиятле хәрби промышленность үзәкләренең берсе булган Штутгартка һөҗүм иткәннәр. Бу шәһәрдә авиация моторлары заводлары, су асты көймәләре өчен двигательләр һәм моторлар өчен запас частьлар эшли торган заводлар бар. Шәһәрнең барлык бистәләрендә дә диярлек зур промышленность һәм химия заводлары урнашкан.

Германия авиациясенең Лондонга һөҗүме

ЛОНДОН, 12 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Германиянең 24 самолетының 12 нче мартта иртә белән Темза тамагы районына килеп чыкканлыкларын хәбәр итә. Самолетларның кайберләре Зур Лондонга барып җиткәннәр һәм бомбалар ташлаганнар, шулай ук урамнарга пулеметлардан атканнар.

Корбан булучылар бар. Лондон бистәләрендә күп кенә кечрәк йортлар җимерелгән.

КОРАЛЛАРНЫ БУРЫЧКА ЯКИ АРЕНДАГА БИРҮ ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫҢ ИКЕ ЕЛЛЫГЫ УңАЕ БЕЛӘН РУЗВЕЛЬТНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ВАШИНГТОН, 11 март. (ТАСС). Бүген, коралларны бурычка яки арендага бирү турында закон чыгуга ике ел тулу уңае белән, бу законны тормышка ашыру уполномоченные Стеттиниус аш мәҗлесе үткәрде һәм шул мәҗлестә АКШ вице-президенты Уэллес Рузвельтның үтенүе буенча, түбәндәге белдерүне укыды.

«Моннан ике ел элек, 1941 нче елның 11 нче мартында, коралларны бурычка яки арендага бирү турында закон кабул ителде. Гитлер, бу сугыш озакка бармас, ул бер генә фронттагы сугыш булыр һәм АКШ ның ярдәме бик кечкенә булыр, бик соңга калыр, дип, үз халкына вәгъдә биргән иде. Япония армиясе вәкилләре дә шундый ук вәгъдә биргәннәр иде. Вакыт бу вәгъдәләрнең ялган икәнлеген күрсәтте. Ә безнең вәгъдәләр сыналудан үттеләр.

Хәзер, без коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы законның ике еллыгын искә алган чакта, берләшкән милләтләр һөҗүм алып баралар. Моннан ике ел элек, күчәр державалары үзләренең икенче ударларын кайда ясарлар дигән мәсьәлә торган иде. Хәзер инде, берләшкән милләтләр үзләренең икенче ударларын кайда ясарлар дигән мәсьәлә тора. Бу мәсьәләгә, без сайлап алган сугыш кырларында дошманга җавап бирелер. Без бер-бер артлы ударлар ясый барган саен коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы закон нигезендә күрсәтелә торган ярдәм һәм үзара булышлык күчәр державаларының котылгысыз җиңелүләренә торган саен күбрәк дәрәҗәдә ярдәм итәр.

Бу үзара булышлык сугышының гомуми коралына караганда, ниндидер зуррак бер нәрсә булып әверелде. Сугышның иң кызу чагында коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы закон гадел һәм ныклы тынычлык тәэмин итү өчен кирәк булачак бердәмлекне булдыруда ярдәм итә».

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Өлкә һәм Шәһәр Комитетларының партия мәгарифе йортында (Бауман урамы, 62) 15 нче мартта, 19 сәгатьтә «К. Маркcның «Капитал» исемле әсәре өстендә ничек эшләргә» дигән темага группалы консультация була; 16 нчы мартта 19 сәгатьтә, «Марксизм-ленинизм классиклары Париж Коммунасы турында» дигән темага лекция була.

Лектор һәм консультант — СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты иптәш Розенберг.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 1/101 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 424